| | |
|---|---|
| СОВЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.03.2020 с.Новые Чути № 124

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советының 18.10.2019 ел, №111 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында:

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 16.12.2009 елдагы 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында " 09.12.2009 елдагы 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 35 статьясына туры китерү максатларында Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советының 18.10.2019 ел, №111 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында:

8 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

21) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында Карар кабул итү.»;

21 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

4. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән билгеләнә»;

31 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

1. Җирлек советы бер мандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланучы 7 депутаттан тора;

92 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

3. Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.
2. Әлеге карарны федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен Юстиция органына җибәрергә.
3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Совет Рәисе
Салих авыл җирлеге башлыгы З. С. Галләметдинов